| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2020 Бима авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 20 ноябрендә 13 сәг 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Бима авылының Ленин, К.Маркс, Хезмәт, М.Горький урамнарында яшәүчеләр.

-2 этап: Бима авылының Нагорная, Совет, Пролетарская, Мәктәп, Яшьләр урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима торак пункты территориясендә, I

төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Бима торак пунктында Пролетарская, М.Горький, Ленин урамы буенча юлларга вак таш түшәү (сатып алу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2. Бима авылында килешү буенча урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, урнаштыру, эш өчен түләү;

3. Бима авылында килешү буенча халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу), эшләр өчен түләү;

4. Бима авылында килешү буенча юлларга хезмәт күрсәтү - урамнарны кардан чистарту, эшләр өчен түләү.

5. Янгын сүндерү машинасын карап тоту, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү

6. Бима торак пунктында зиратны карап тоту (эш өчен шартнамә буенча материаллар сатып алу һәм түләү).

7. Бима торак пунктында мәдәният йорты территориясен койма белән урап алу һәм материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Бима ав., Ленин ур., 1 адресы буенча мәдәният йортында уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.И.Михайлов